# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Балтач муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 13 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Балтач муниципаль районы составына керүче "Балтач шәһәр тибындагы поселогы", "Кече Лызи авыл җирлеге" һәм "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


"Балтач муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 8 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балтач муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

## "Балтач муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 17(13)-1(Б) | - Марий Эл Республикасы |
| 1(Б)-25(14) | - Киров өлкәсе |
| 25(14)-38(51) | - Кукмара муниципаль районы |
| 38(51)-37(50) | - Саба муниципиальрайоны |
| 37(50)-17(13) | - Арча муниципаль районы |

"Балтач муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Балтач шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Борбаш авыл җирлеге |
| 3 | Борнак авыл җирлеге |
| 4 | Югары Субаш авыл җирлеге |
| 5 | Карадуган авыл җирлеге |
| 6 | Куныр авыл җирлеге |
| 7 | Кече Лызи авыл җирлеге |
| 8 | Норма авыл җирлеге |
| 9 | Нөнәгәр авыл җирлеге |
| 10 | Пыжмара авыл җирлеге |
| 11 | Салавыч авыл җирлеге |
| 12 | Смәил авыл җирлеге |
| 13 | Сасна авыл җирлеге |
| 14 | Урта Көшкәт авыл җирлеге |
| 15 | Чепья авыл җирлеге |
| 16 | Шеңшеңәр авыл җирлеге |
| 17 | Шубан авыл җирлеге |
| 18 | Яңгул авыл җирлеге"; |

2) 3 нче кушымтада:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Норма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба, Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м көньякка таба уза, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 550 м көнчыгышка таба, аннары көньяк-көнбатышка таба озын чокырның көнбатыш чиге буйлап 500 м һәм чокырның көнбатыш чиге буйлап 550 м, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 20 м бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км Норма елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 900 м бара, "Казан – Малмыж" – Нормабаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң

1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 900 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Норма һәм Кече Лызи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чиге Кече Лызи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталына кадәр 1,0 км уза, шуннан соң бу урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 180 м бара, "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 81, 80 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 76, 74, 72 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,4 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 72 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 20 м төньяк-көнбатышка таба бара, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,0 км төньяк-көнчыгышка бара, аннары, юл буендагы урман полосасын һәм Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 1,5 км, 400 м көньяк-көнбатышка һәм 800 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км төньякка һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 60 нчы урман кварталына кадәр бара, аннары әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м төньякка һәм төньяк чиге буйлап 500 м көнбатышка таба уза, аннары, Балтач – Кенәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнбатышка бара, аннары, юл буендагы урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м төньяк-көнбатышка, 900 м төньяк-көнчыгышка, 150 м көньяк-көнчыгышка, 300 м төньяк-көнчыгышка "Балтач – Кенәбаш"– Олы Лызи автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 200 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньякка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м көнчыгышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 400 м төньяк-көнчыгышка таба 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

3) 9 нчы кушымтаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кече Лызи авыл җирлеге чиге "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Кече Лызи һәм Норма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Көекбаш авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталына кадәр 1,0 км уза, шуннан соң бу урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 180 м бара, "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 81, 80 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 76, 74, 72 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,4 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 72 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 20 м төньяк-көнбатышка таба, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,0 км төньяк-көнчыгышка бара, аннары, юл буендагы урман полосасын һәм Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 1,5 км, көньяк-көнбатышка 400 м һәм төньяк-көнбатышка таба 800 м уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км төньякка һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Арча урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтач участок урманчылыгындагы 60 нчы урман кварталына кадәр бара, аннары әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м төньякка һәм төньяк чиге буйлап 500 м көнбатышка таба уза, аннары, Балтач – Кенәбаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнбатышка бара, аннары, юл буендагы урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м төньяк-көнбатышка, 900 м төньяк-көнчыгышка, 150 м көньяк-көнчыгышка, 300 м төньяк-көнчыгышка "Балтач – Кенәбаш"– Олы Лызи автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 200 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньякка таба, 400 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м көнчыгышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 400 м төньяк-көнчыгышка таба 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 10 нчы кушымтаның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Норма авыл җирлеге чиге "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге, Норма һәм Сасна авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шушма елгасы үзәнендә Балтач шәһәр тибындагы поселогыннан 750 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба, Балтач – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м көньякка таба уза, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 550 м көнчыгышка таба, аннары көньяк-көнбатышка таба озын чокырның көнбатыш чиге буйлап 500 м һәм чокырның көнбатыш чиге буйлап 550 м, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 20 м бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км Норма елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 900 м бара, "Казан – Малмыж" – Нормабаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 900 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.".

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2012 елның 29 сентябре
№ 66-ТРЗ

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Балтач муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Муниципаль берәмлекләр чикләренең тәкъдим ителгән үзгәрешләр исәпкә алынган <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

 - муниципаль берәмлекләр чикләре

 - Балтач муниципаль районы чиге

 - җирлекләрнең административ үзәкләре

 - торак пунктлар

 - Балтач муниципаль районының "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясе

 - Балтач муниципаль районының "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясе